КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 декабрь г.Казань № 1767

«Шикәр диабеты белән көрәш» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларына мохтаҗ 1 типтагы шикәр диабеты белән авыручы балаларны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклау системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1640 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Шикәр диабеты белән көрәш» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларына мохтаҗ 1 типтагы шикәр диабеты белән авыручы балаларны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 декабрь, 1767 нче
карары белән расланды

«Шикәр диабеты белән көрәш» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларына мохтаҗ 1 типтагы шикәр диабеты белән авыручы балаларны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибе

1. Әлеге Тәртиптә «Шикәр диабеты белән көрәш» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларына мохтаҗ 1 типтагы шикәр диабеты белән авыручы балаларны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү механизмы билгеләнә.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган «балалар эндокринологиясе» юнәлеше буенча медицина ярдәме стандартлары һәм клиник тәкъдимнамәләр нигезендә глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларына (шул исәптән Россиядә җитештерелгәннәргә) мохтаҗ 1 типтагы шикәр диабеты белән авыручы балаларны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган федераль бюджеттан субсидия (алга таба – субсидия) (алга таба – бюджет акчалары) исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Субсидия түбәндәге чараларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә:

а) 1 типтагы шикәр диабеты белән авыручы 2 яшьтән 4 яшькә кадәрге балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү;

б) 1 типтагы шикәр диабеты белән авыручы 4 яшьтән 17 яшькә (17 яшьне кертеп) кадәрге балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү.

3. Бюджет акчалары белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

4. Бюджет акчаларын тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарына таянып, әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларын сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзи;

глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларын сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзелгән оешмаларга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) шартлары нигезендә акча күчерә.

1 типтагы шикәр диабеты белән авыручы балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү табиблар рецептлары буенча аптека оешмалары аша гамәлгә ашырыла.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә, форма буенча һәм срокларда финанслашу максатларында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында, шулай ук субсидиядән файдалану нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисаплар урнаштыра.

8. Бюджет акчаларын максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җавап бирелә.

9. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына субсидиянең файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

---